**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**ГОРОДА ЛАИШЕВО**

ул. Коммунальная,
д.3,г.Лаишево,422610

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЛАЕШ ШӘҺӘРЕ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Коммунальная ур., 3 нче йорт,
Лаеш ш.,422610

тел: 8-(84378) -2-57-77, факс: 8-(84378) -2-50-62, e-mail:Gorod.La@tatar.ru

**2020 елның « 11 » сентябре** **47номер**

# КАРАР

**Рөхсәт ителгән төзелешнең**
**чик параметрларыннан**
**читкә тайпылуга рөхсәт**
**бирү турында**

Сәлахиева Гөлнур Әлтәф кызының Татарстан Республикасы, Лаеш муниципаль районы, Лаеш шәһәре адресы буенча урнашкан, кадастр номеры 16:24:170151:24 булган җир кишәрлеге өчен рөхсәт бирү турындагы мөрәҗәгатен карап, 2004 елның 29 декабрендәге 190-ФЗ номерлы РФ Шәһәр төзелеше кодексы, «Лаеш шәһәре» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре нигезендә, гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмәне исәпкә алып, Лаеш муниципаль районының башкарма комитеты карар бирә:

1. Сәлахиева Гөлнур Әлтәф кызына, Татарстан Республикасы, Лаеш муниципаль районы, Лаеш шәһәре адресы буенча урнашкан, кадастр номеры 16:24:170151:24 булган җир кишәрлеге өчен кишәрлек чикләреннән көнбатыш яктан торак йортка кадәр 3 метрдан 1,2 метрга кадәр минималь чиген киметү өлешендә рөхсәт ителгән төзелешнең чик параметрларыннан читкә тайпылуга рөхсәт бирергә.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче В.А. Арефьев